# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

## Үсемлекләр дөньясы турында

Үсемлекләр дөньясы - биосфераның актив рәвештә органик матдә һәм ирекле кислород җитештерүче, табигатьтәге матдәләр алмашын тотып торуда аеруча зур әһәмияткә ия төп компонентларыннан берсе, ул - Җирдәге тереклекнең барышын билгеләүче фактор һәм төрле яклап саклануга һәм нәтиҗәле файдалануга мохтаҗ.

Әлеге Закон үсемлекләр дөньясын саклау, аннан фәнни нигездә һәм нәтиҗәле файдалану өлкәсендә Татарстан Республикасының дәүләт сәясәте принципларын ныгыта, бу өлкәдә хокукый, икътисадый һәм социаль нигезләрне билгели һәм үсемлекләр дөньясы байлыкларын саклап калуга һәм яңадан торгызуга юнәлдерелә.

### I бүлек. Гомуми нигезләмәләр

#### 1 статья. Төп төшенчәләр

Әлеге Закон максатларында түбәндәге төп төшенчәләр кулланыла:

Үсемлекләр дөньясы - барлык төр кәпшәсыман үсемлекләрнең, мүкләрнең, лишайникларның, суүсемнәрнең һәм гөмбәләрнең, кыргыйларының да, культуралыларының да, республика территориясендә үсүче биологик күптөрлелегенең һәм табигать мохитенең башка компонентлары белән үзара бергәлеге ул.

Үсемлекләр дөньясы объектлары - үсемлекләр дөньясын тәшкил итүче теләсә нинди организм, әлеге организмнарның табигый һәм ясалма оешкан бергәлекләре ул.

157



Үсү урыннары - үсемлекләр дөньясы объектлары яшәеше һәм үсүе өчен кирәкле экологик шартлар тудыручы җир, су, һава киңлекләре ул.

Үсемлекләр дөньясы объектларыннан файдалану - үсемлекләр дөньясы объектларын хуҗалык итү, мәдәни, эстетик һәм башка максатларда куллану буенча юридик нигезләнгән эшчәнлек ул.

Үсемлекләр дөньясыннан файдаланучылар - Татарстан Республикасы законы нигезендә үсемлекләр дөньясы объектларыннан файдалану хокукы бирелгән физик һәм юридик затлар ул.

Табигый үсемлек байлыклары - кыргый үсемлекләрнең, гөмбәләрнең һәм аларны барлыкка китерүче бергәлекләрнең табигый байлыклары, җимешләр, орлыклар һәм аларның башка өлешләре яисә кыргый үсемлекләрнең һәм гөмбәләрнең матди байлыклар тудыруга ярдәм итүче тормыш эшчәнлеге продуктлары ул.

Лицензия - үсемлекләр дөньясы объектларын файдалануга бәйле һәм шунда күрсәтелгән хуҗалык эшчәнлеген башкару хокукы бирүче махсус рөхсәт ул.

Бер генә мәртәбә бирелүче лицензия - аерым бер территориядә, акваториядә үсемлекләр дөньясы объектларының кайберләреннән генә һәм билгеле бер күләмдә бер генә мәртәбә файдалану хокукы бирүче яисә бу хокукны мәгълүм бер вакытка гына бирүче махсус рөхсәт ул.

2 статья. Үсемлекләр дөньясын саклау һәм аннан нәтиҗәле файдалану турында Татарстан Республикасы законнары

Татарстан Республикасы территориясендә үсемлекләр дөньясы объектларын биләгәндә, алардан файдаланганда һәм алар белән эш иткәндә барлыкка килүче мөнәсәбәтләр Татарстан Республикасы Конституциясенә нигезләнә, табигатьне саклау турындагы законнар, әлеге Закон һәм Татарстан Республикасының башка закон актлары белән җайга салына.

Әлеге Закон физик һәм юридик затларның шәхси милек хокукындагы җирләрендә яисә авыл хуҗалыгы үсемлекчелеге, бакчачылык һәм яшелчәчелек үрчетү максатларында хуҗа булган башка җирләрдә үстерелүче үсемлекләр дөньясы объектларын биләгәндә, алардан файдаланганда һәм алар белән эш иткәндә барлыкка килү-

че мөнәсәбәтләрне җайга салмый.

3 статья. Үсемлекләр дөньясы турындагы Татарстан Республикасы законнарының максатлары

Үсемлекләр дөньясы турындагы Татарстан Республикасы законнарының төп максатлары түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

үсемлекләр дөньясы объектларының үсүе өчен уңай шартларны саклау һәм аларның биологик күптөрлелеген саклап калу, халык ихтыяҗларын канәгатьләндерү максатларында үсемлекләр дөньясы объектларын саклау һәм алардан нәтиҗәле файдалану өлкәсендәге мөнәсәбәтләрне җайга салудан;

үсемлекләр дөньясы объектларыннан файдаланучыларның - физик һәм юридик затларның хокукларын һәм бурычларын билгеләүдән;

үсемлекләр дөньясы объектларын саклау һәм алардан нәтиҗәле файдалану өлкәсендәге хокук бозулар өчен җаваплылык гамәлләре билгеләүдән.

4 статья. Үсемлекләр дөньясына карата милекчелек

Татарстан Республикасы территориясендә табигый шартларда үсүче үсемлекләр дөньясы бөтен халык байлыгы була.

Үсемлекләр дөньясы объектлары хосусый, дәүләт (шул исәптән республика һәм коммуналь) милкендә, җирле үзидарә һәм җәмәгать берләшмәләре милкендә булырга мөмкин.

## 2 бүлек.
## Үсемлекләр дөньясын саклау һәм аннан нәтиҗәле файдалану өлкәсендә дәүләт идарәсе

5 статья. Үсемлекләр дөньясын саклау һәм аннан нәтиҗәле файдалану өлкәсендә дәүләт идарәсе

Үсемлекләр дөньясын саклау һәм аннан нәтиҗәле файдалану өлкәсендә дәүләт идарәсе түбәндәгеләрдән гыйбарәт: үсемлекләр дөньясын дәүләт тарафыннан исәпкә алудан һәм аның дәүләт кадастрын алып барудан, үсемлекләр дөньясы объектларын саклауны, яңадан торгызуны һәм алардан файдалануны дәүләт тарафыннан

тикшереп торудан һәм үсемлекләр дөньясы объектларының мониторингын гамәлгә ашырудан.

Үсемлекләр дөньясын саклау һәм аннан нәтиҗәле файдалану өлкәсендә дәүләт идарәсен Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты, Татарстан Республикасының әйләнә-тирә мохитне һәм табигый байлыкларны саклау министрлыгы, Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы һәм үсемлекләр дөньясы объектларын саклау, алардан файдалануны җайга салу буенча дәүләтнең махсус вәкаләтле башка органнары гамәлгә ашыра.

<u>6 статья.</u> Үсемлекләр дөньясын саклауның һәм аннан нәтиҗәле файдалануның төп принциплары

Үсемлекләр дөньясын саклау һәм аннан нәтиҗәле файдалануның төп принциплары түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

үсемлекләр дөньясының тотрыклы яшәешен һәм үсеш тирәлегенең сакланышын тәэмин итүгә юнәлдерелгән эшчәнлекнең өстенлегеннән;

үсемлекләр дөньясыннан нәтиҗәле һәм фәнни нигездә файдаланудан, аның биологик күптөрлелеген саклап калуның һәм аны яңадан торгызуның зарурлыгыннан, аның үсеш тирәлеге өчен зарарлы күренешләрне булдырмый калудан;

үсемлекләр дөньясыннан махсус файдалануның түләүле һәм гомуми файдалануның түләүсез булуыннан;

үсемлекләр дөньясы объектларын файдалану хокукының гражданнар өчен тигез булуыннан һәм бу өлкәдәге социаль гаделлектән;

үсемлекләр дөньясын саклау һәм аннан нәтиҗәле файдалану өлкәсендә дәүләтнең тикшереп тору вазыйфаларын үсемлекләр дөньясы объектларын хуҗалык итү ягыннан файдалану вазыйфаларына алмаштыру рөхсәт ителмәүдән;

үсемлекләр дөньясы турындагы законнарның таләпләрен катгый үтәүдән, аларны бозган өчен җаваплылыкның котылгысыз булуыннан;

үсемлекләр дөньясыннан нәтиҗәле файдалану һәм аны саклау бурычларын хәл итүнең хәбәрдарлыгыннан һәм иҗтимагый оешмалар, халык белән элемтәдә торудан.

7 статья. Үсемлекләр дөньясы объектларын саклау һәм аннан нәтиҗәле файдалану өлкәсендә махсус вәкаләтле дәүләт органнарының вәкаләтләре

Үсемлекләр дөньясын саклау һәм аннан нәтиҗәле файдалану өлкәсендә Татарстан Республикасының махсус вәкаләтле дәүләт органнары карамагына түбәндәгеләр керә:

үсемлекләр дөньясы объектларының кайбер төрләреннән файдалануны дәүләт тарафыннан тикшереп торуны һәм җайга салуны оештыру һәм башкару;

үсемлекләр дөньясы объектларының кайбер төрләреннән файдалану өчен лицензияләр бирү;

үсемлекләр дөньясы объектларының кайбер төрләреннән файдалануның кагыйдәләрен, аларны табигатьтән аерып алуның лимитларын һәм квоталарын әзерләү;

үсемлекләр дөньясы объектларының кайбер төрләрен исәпкә алу һәм аларның халәтенә бәя бирү;

үсемлекләр дөньясы объектларының кайбер төрләре халәте турында мәгълүматлар җыю, саклау, эшкәртү, анализлау һәм тарату.

8 статья. Үсемлекләр дөньясы объектларын дәүләт тарафыннан исәпкә алу һәм аларның дәүләт кадастры

Үсемлекләр дөньясын саклау һәм аның объектларыннан нәтиҗәле файдалануны оештыру йөзеннән, үсемлекләр дөньясы объектлары һәм алардан файдалану дәүләт тарафыннан исәпкә алына һәм үсемлекләр дөньясы объектларының кадастры алып барыла.

Үсемлекләр дөньясы объектларының дәүләт кадастры үсемлекләр дөньясы объектларының географик таралуы, аларның саны турындагы белешмәләр җыелмасыннан, үсемлекләр дөньясы байлыкларының яшәү тиршлеге сыйфатламасыннан, аларны хуҗалык итүдә куллану хакындагы мәгълүматлардан һәм башка кирәкле белешмәләрдән, шулай ук дендропаркларда, ботан бакчаларында, питомникларда тупланган үсемлекләр дөньясы объектлары турындагы белешмәләрдән гыйбарәт.

Үсемлекләр дөньясыннан файдаланучылар - юридик затлар үзләре кулланган үсемлекләр дөньясы объектларын һәм табигатьтән

зерып алганнарының күләмнәрен исәпкә алырга һәм шушы мәгълүматларны үсемлекләр дөньясы объектларын саклау һәм алардан нәтиҗәле файдалану өлкәсендәге Татарстан Республикасының махсус вәкаләтле тиешле дәүләт органнарына тапшырырга тиеш.

Үсемлекләр дөньясы объектларын дәүләт тарафыннан исәпкә алу һәм дәүләт кадастрын алып бару Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты билгеләгән тәртиптә гамәлгә ашыра.

9 статья. Үсемлекләр дөньясы объектларының дәүләт мониторингы

Үсемлекләр дөньясы объектларының дәүләт мониторингы - үсемлекләр дөньясы объектларының үзгәрешләрен үз вакытында ачыклау, аларга бәя бирү, фаразлау, тискәре процессларны булдырмый калу һәм бетерү йөзеннән, аларның халәтен, санын һәм таралышын, шулай ук аларның яшәеш тирәлегенең төзелешен һәм сыйфатын даими рәвештә күзәтеп тору системасы ул.

Үсемлекләр дөньясы объектларының дәүләт мониторингын алып бару тәртибе Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты тарафыннан билгеләнә.

3 бүлек.
Үсемлекләр дөньясы объектларын саклау һәм яңадан торгызу

10 статья. Үсемлекләр дөньясы объектларын саклау һәм аларны яңадан торгызуны тәэмин итү гамәлләре

Үсемлекләр дөньясы объектларын саклау һәм аларны яңадан торгызу түбәндәгечә тәэмин ителә:

үсемлекләр дөньясы объектларын саклау, яңадан торгызу һәм алардан нәтиҗәле файдалану өлкәсендә нормалар һәм кагыйдәләр билгеләү һәм аларның үтәлешен тикшереп тору;

үсемлекләр дөньясыннан файдалануда тыюлар һәм чикләүләр билгеләү;

үсемлекләр дөньясыннан рөхсәтсез файдалануны һәм үсемлекләр дөньясыннан файдалануның билгеләнгән тәртипләрен башкача бозуларны булдырмый калу;

үсемлекләр дөньясы объектлары үсеш тирәлегенең уңайлы халәтен саклап калу;

хуҗалык эшчәнлеген башкарганда үсемлекләр дөньясы объектларын зарарланудан һәм һәлак булудан саклап калу;

махсус саклanылучы табигать территорияләре булдыру;

сирәк очрый торган һәм бетү куркынычы булган үсемлек, гөмбә төрләрен һәм үсемлекләрнең уникаль бергәлеген саклау;

үсемлекләр дөньясы объектларын үрчетү, аларның генетик фондын саклап калу һәм табигый яшәеш тирәлегендә яңадан торгызу буенча махсуслаштырылган үзәкләр (ботан бакчалары, дендробакчалар, питомниклар һәм башкалар) оештыру;

үсемлекләр дөньясы объектларының күпләп зарарлануын һәм аларның авыру чыганаклары барлыкка килүне һәм җәелүне булдырмау өчен биотехник гамәлләр уздыру;

үсемлекләр дөньясы объектларын саклау, яңадан торгызу һәм алардан нәтиҗәле файдалану өлкәсендә фәнни тикшеренүләр оештыру;

хуҗалык проектларына экология экспертизасы ясау һәм үсемлекләр дөньясы объектларының яшәү тирәлегенә йогынты ясарлык гамәлдәге хуҗалык корылмаларын һәм предприятиеләрен тикшереп тору;

үсемлекләр дөньясын саклауны пропагандалау һәм халыкка экологик белем бирү;

үсемлекләр дөньясы объектларын һәм аларның яшәү тирәлеген саклау буенча законнар нигезендә башка гамәлләр уздыру һәм башка төр таләпләр билгеләү.

Үсемлекләр дөньясы объектларын саклау һәм яңадан торгызу буенча башкарылучы гамәлләр әйләнә-тирә табигать мохитенең башка объектларына зыян китермәскә тиеш.

<u>11 статья.</u> Дәүләт экология экспертизасы

Үсемлекләр дөньясы объектларына һәм аларның яшәеш тирәлегенә йогынты ясарлык хуҗалык карарларын кабул иткәнче, үсемлекләр дөньясын саклауның мәҗбүри гамәле буларак, дәүләт экология экспертизасы үткәрелергә тиеш.

Түбәндәгеләр мәҗбүри рәвештә дәүләт экология экспертизасы

үтәргә тиеш: техник-икътисадый нигезләүләр, предприятиеләрне, корылмаларны һәм башка объектларны урнаштыру һәм төзү проектлары, шулай ук үсемлекләр дөньясы объектларын бирү, куллану һәм табигатьтән зарып алу белән бәйле технологик процесслар, яңа техника, химик матдәләр һәм препаратлар, норматив-техник документлар, проектлар.

Дәүләт экология экспертизасын законнар нигезендә Татарстан Республикасының Әйләнә-тирә мохитне һәм табигый байлыкларны саклау министрлыгы үсемлекләр дөньясы объектларын саклау һәм алардан нәтиҗәле файдалану буенча дәүләтнең махсус вәкаләтле башка органнары белән берлектә башкара.

12 статья. Үсемлекләр дөньясы объектларыннан файдалануга чикләүләр һәм тыюлар билгеләү

Үсемлекләр дөньясын һәм аларның яшәеш тирәлеген саклап калу һәм яңадан торгызу йөзеннән, үсемлекләр дөньясының зерым төрләреннән файдалану, шулай ук үсемлекләр дөньясының кайбер объектларыннан файдалану Татарстан Республикасының Әйләнә-тирә мохитне һәм табигый байлыкларны саклау министрлыгы, Татарстан Республикасының Урман хуҗалыгы министрлыгы тәкъдиме буенча Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты карары нигезендә билгеле бер территорияләрдә һәм акваторияләрдә яисә билгеле бер вакытка чикләнергә, туктатып торылырга яисә бөтенләй тыелырга мөмкин.

Үсемлекләр дөньясы объектларын саклауга үсемлекләр дөньясыннан файдалану төрен үзгәртү, үсемлекләр дөньясы объектларын яшәеш тирәлекләреннән зарып алуны тыю, әлеге объектларны, зарып алмыйча гына, мәдәни-агарту, ял итү һәм зәүкый максатларда файдалануны оештыру (моңа экологик туризмны оештыру да керә) юллары белән ирешелергә мөмкин.

13 статья. Үсемлекләр дөньясы объектларының яшәеш тирәлеген саклау

Үсемлекләр дөньясы объектларының яшәеш тирәлеген, вегетация һәм үрчү шартларын үзгәртерлек теләсә нинди эшчәнлек үсемлекләр дөньясын саклауны тәэмин итәрлек таләпләрне үтәгән ки-

леш кенә гамәлгә ашырыла.

Торак пунктларын, предприятиеләрне, корылмаларны һәм башка объектларны урнаштырганда, проектлаштырганда һәм төзегәндә, гамәлдәге технологик процессларны камилләштергәндә һәм яңаларын гамәлгә керткәндә, сазлыкларны, яр буендагы һәм куаклыклар биләгән территорияләрне хуҗалык әйләнешенә керткәндә, җирләрне мелиорацияләгәндә, урманнардан файдаланганда, геологик эзләнү эшләрен башкарганда, файдалы казылмалар чыгарганда, авыл хуҗалыгы терлекләрен көтү һәм йөртү урыннарын билгеләгәндә, туристик маршрутларны әзерләгәндә һәм халыкның күпләп ял итү урыннарын оештырганда, хуҗалык эшчәнлегенең башка төрләрен гамәлгә ашырганда, үсемлекләр дөньясы объектларының яшәеш тирәлеген саклау гамәлләре күз алдында тотылырга һәм үтәлергә тиеш.

Үсемлекләр дөньясы объектларының сирәк очрый торган, юкка чыгу куркынычы астында булган һәм хуҗалык итү һәм фәнни яктан кыйммәтле объектларын саклауны тәэмин итү йөзеннән, алар үсә торган һәм аларның тереклеге өчен кирәкле территорияләрдә һәм акваторияләрдә якланылучы кишәрлекләр бүлеп алына. Территорияләрнең һәм акваторияләрнең якланылучы кишәрлекләрендә хуҗалык эшчәнлегенең кайбер төрләре тыела яисә үсемлекләр дөньясы объектларының яшәеш циклын бозарлык технологияләрне үткәрү һәм аның вакыты җайга салына.

Якланылучы кишәрлекләр Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты карары буенча оештырыла, бу очракта аларга Татарстан Республикасының әйләнә-тирә мохитне һәм табигый байлыкларны саклау министрлыгы тәкъдиме буенча дәүләт табигать тыюлыклары статусы бирелә. Хуҗалык эшчәнлеген чикләү юлы белән якланылучы кишәрлекләр бүлеп бирелгәндә, якланылучы кишәрлекләрнең милекчесенә, биләүчесенә яисә арендаторына Татарстан Республикасы законнары нигезендә компенсация түләнә.

<u>14 статья.</u> Махсус сакланылучы табигать территорияләрендә һәм акваторияләрендә үсемлекләр дөньясы объектларын саклау

Дәүләт табигать тыюлыкларының һәм милли табигать парклары тыюлык зоналарының территорияләрендә үсемлекләр дөньясыннан

аларның максатларына туры килмәслек итеп файдалануның барлык төрләре, шулай ук үсемлекләрнең табигый бергәлегенең яшәеш тирәлеген үзгәртерлек теләсә нинди эшчәнлек тыела.

Дәүләт табигать тыюлыклары территорияләрендә үсемлекләр дөньясы объектларыннан мәдәни-агарту, тәрбияви, ял итү һәм зәүкый максатларда файдалану әлеге сакланылучы зоналар чикләрендә генә рөхсәт ителә, ә милли паркларда - музей экспозицияләре, күзәтү мәйданнары һәм табигать белән, үсемлекләр дөньясы белән танышуны тәэмин итүче башка корылмалар куелган махсус бүлеп бирелгән кишәрлекләрдә генә рөхсәт ителә.

Махсус сакланылучы табигать территорияләрендә үсемлекләр дөньясы объектларының санын һәм биомассасын җайга салучы гамәлләр бары тик Татарстан Республикасының Әйләнә-тирә мохитне һәм табигый байлыкларны саклау министрлыгы белән килешенеп кенә гамәлгә ашырылалар.

**15 статья.** Үсемлекләр дөньясының сирәк очрый торган һәм юкка чыгу куркынычы булган объектларын саклау

Үсемлекләр дөньясының сирәк очрый торган һәм юкка чыгу куркынычы булган объектлары Татарстан Республикасының Кызыл китабына кертелә.

Үсемлекләр дөньясының Кызыл китапка кертелгән объектларын һәлак булуга, аларның санын киметүгә, аларның таралыш киңлекләрен тарайтуга яисә аларның яшәеш тирәлеген бозуга китергән гамәлләр рөхсәт ителми.

Тиешле махсус оешмаларның Кызыл китапка кертелгән үсемлекләрне һәм гөмбәләрне кулга төшерүе, сатып алуы, алар белән, шулай ук аларны эшкәртү продуктлары белән сәүдә итүе, аларны Татарстан Республикасыннан читкә чыгаруы бары тик Татарстан Республикасының Әйләнә-тирә мохитне һәм табигый байлыкларны саклау министрлыгы рөхсәте буенча гына гамәлгә ашырыла.

**16 статья.** Үсемлекләр дөньясы объектларын климатлаштыру

Татарстан Республикасы флорасы өчен яңалык булган үсемлекләр дөньясы объектларын климатлаштыру белән бәйле гамәлләрне башкару бары тик Татарстан Республикасының Әйләнә-тирә мо-

хитне һәм табигый байлыкларны саклау министрлыгы рөхсәте буенча һәм вәкаләтле фәнни оешмаларның экологик иминлек таләпләрен исәпкә алып бирелгән уңай бәяләмәсе булганда гына рөхсәт ителә. Үсемлекләр дөньясы объектларын рөхсәтсез күчереп утырту һәм климатлаштыру тыела.

17 статья. Җитештерү эшләрен башкарганда үсемлекләр дөньясы объектларының күпләп авыруларын һәм корткычларның таралуын булдырмау

Авыл хуҗалыгы эшләрен һәм башка эшләрне башкарганда, шулай ук сугару һәм мелиорация системасыннан, транспорт чараларыннан файдаланганда юридик һәм физик затлар үсемлекләр дөньясы объектларының күпләп авыруларын һәм корткычларның таралуын булдырмау буенча чаралар күрергә тиеш.

Татарстан Республикасының Урман хуҗалыгы министрлыгы, Татарстан Республикасының Әйләнә-тирә мохитне һәм табигый байлыкларны саклау министрлыгы, Татарстан Республикасының Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы үсемлекләр дөньясы объектлары корткычларының һәм авыруларының чыганаклары барлыкка килүне һәм таралуны тикшереп торалар һәм үсемлекләр дөньясы объектлары корткычларының һәм авыруларының күпләп таралуын булдырмау өчен тиешле чаралар күрәләр.

Үсемлекләрне саклый торган химик препаратларны һәм үсемлекләр дөньясына тискәре йогынты ясый торган башка препаратларны куллану агротехник, селекция-генетик, биологик һәм башка гамәлләрне башкару белән бергә алып барылырга тиеш.

Бу химик һәм биологик препаратларны әзерләү, тәҗрибәләр уздыру кагыйдәләре, аларны куллануның регламенты һәм нормативлары, шулай ук аларның исемлеге Татарстан Республикасының Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы, Татарстан Республикасының Урман хуҗалыгы министрлыгы тәкъдиме буенча Татарстан Республикасының Әйләнә-тирә мохитне һәм табигый байлыкларны саклау министрлыгы һәм Татарстан Республикасының Санитария-эпидемиология күзәтүе буенча дәүләт комитеты тарафыннан раслана.

18 статья. Үсемлекләр дөньясы объектларының исәбен һәм таралуын җайга салу

Авыл хуҗалыгы культураларының авыруларын һәм аларның зәгыйфьләнүен булдырмау, үсемлекләр дөньясына һәм аларның үсеш тирәлегенә зыян килүне булдырмау максатларында үсемлекләр дөньясының аерым объектларының исәбен һәм таралуын җайга салу буенча чаралар күрелә.

Үсемлекләр дөньясының аерым объектларының исәбен һәм таралуын җайга салу, Татарстан Республикасының Әйләнә-тирә мохитне һәм табигый байлыкларны саклау министрлыгы белән килешенеп, үсемлекләр дөньясының башка объектларына зыян китерми торган һәм аларның яшәү тирәлегенең сакланышын тәэмин итә торган ысуллар белән гамәлгә ашырылырга тиеш.

Татарстан Республикасының урман фондында башкарылучы әлеге гамәлләр Татарстан Республикасының Урман кодексы нигезендә тормышка ашырыла.

19 статья. Ботаника коллекцияләре

Фәнни, мәдәни-агарту, укыту-тәрбияви һәм зәүкый кыйммәткә ия ботаника коллекцияләре (институтларның, университетларның, музейларның фәнни фондлары коллекцияләре, шулай ук гербарийларның, үсемлекләр дөньясы объектлары препаратларының һәм өлешләренең җыелмасы, ботан һәм дендрология бакчаларының, питомникларның, аквариумнарның һәм башка учреждениеләрнең флора коллекцияләре) дәүләт тарафыннан исәпкә алынырга тиеш.

Гербарийларның яисә аерым экспонатларның ботаника коллекцияләрен дәүләт тарафыннан исәпкә алу, тулыландыру, саклау, сатып алу, сату, күчереп җибәрү, Татарстан Республикасыннан читкә чыгару, аңа кертү тәртибе Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты тарафыннан билгеләнә.

Шундый коллекцияләрнең хуҗалары аларны исәпкә алуның, саклауның, тулыландыруның һәм алардан файдалануның Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты тарафыннан билгеләнүче тәртибен үтәргә тиешләр.

168



## 4 бүлек.
## Үсемлекләр дөньясыннан файдалану

20 статья. Үсемлекләр дөньясыннан файдалану төрләре

Татарстан Республикасы территориясендә үсемлекләр дөньясыннан файдалануның түбәндәге төрләре гамәлгә ашырылырга мөмкин:

урман хуҗалыгы;

авыл хуҗалыгы үсемлекләрен үстерү, бакчачылык һәм яшелчәчелек;

кыргый техник һәм дару чималын әзерләү;

үсемлекләр дөньясыннан фәнни, мәдәни-агарту, тәрбияви, ял итү, зәүкый һәм башка максатларда файдалану;

үсемлекләр дөньясы объектлары эшчәнлегенең файдалы үзенчәлекләреннән файдалану - яңа төр туфрак булдыру, атмосфераны үз халәтенә кайтару, биофильтрлау h.б.;

үсемлекләр дөньясы объектларыннан аларның яшәеше өчен кирәкле продуктлар алу максатларында файдалану.

21 статья. Үсемлекләр дөньясыннан файдалану шартлары

Үсемлекләр дөньясыннан озак вакытка файдалану хокукы шартнамә һәм лицензия нигезендә билгеләнә.

Табигый үсеш тирәлегеннән лицензиясез аерып алынулары (махсус файдалану) тыелган үсемлекләр дөньясы объектларының исемлеге үсемлекләр дөньясын саклау һәм аннан нәтиҗәле файдалану өлкәсендә Татарстан Республикасының махсус вәкаләтле органнары тарафыннан билгеләнә.

Үсемлекләр дөньясыннан махсус файдалану юридик затларга - лицензия нигезендә, гражданнарга Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты тарафыннан билгеләнә торган тәртиптә һәм күләмнәрдә түләнгән бер мәртәбәле исемле лицензия нигезендә рөхсәт ителә.

Үсемлекләр дөньясын табигый яшәеш тирәлегеннән аерып алып һәм аерып алмыйча гомуми файдалану түләүсез була.

Үсемлекләр дөньясыннан файдалану әлеге Закон һәм Татарстан Республикасының башка хокукый-норматив актлары ниге-

зендә әзерләнүче стандартларны, кагыйдәләрне, лимитларны һәм нормативларны үтәгән килеш башкарыла.

Үсемлекләр дөньясыннан файдалану үсемлекләр дөньясы объектларын саклау һәм ишәйтү, аларның үсеш тирәлеген саклау буенча системалы чаралар белән бергә гамәлгә ашырыла.

Әгәр үсемлекләр дөньясыннан файдалану төрләре бер-берсенә комачауламаса, бер үк территориядә яисә акваториядә аның берничә төреннән файдаланырга мөмкин.

22 статья. Үсемлекләр дөньясыннан файдаланучы юридик затларның хокуклары һәм бурычлары

Үсемлекләр дөньясыннан файдаланучылар түбәндәгеләргә хокуклы:

үсемлекләр дөньясының әзерләнгән объектларына һәм алардан алынган продукциягә милекчелек хокукына;

үсемлекләр дөньясыннан файдалануның рөхсәт ителгән төрләрен гамәлгә ашыру барышында алынган продукцияне эшкәртергә, үсемлекләр дөньясы объектларыннан әйберләр җитештерергә;

җитештерелгән продукцияне сатарга;

юридик затларның һәм гражданнарның хокукка каршы гамәлләре белән китерелгән зыянга карата законнарда билгеләнгән тәртиптә дәгъва белдерергә;

җир биләүчеләр (җирдән файдаланучылар), урман фондын биләүчеләр белән, үсемлекләр дөньясын саклау, аннан нәтиҗәле файдалану өлкәсендә Татарстан Республикасының махсус вәкаләтле дәүләт органнары белән килештереп, үсемлекләр дөньясы объектларының үсеш тирәлегенә аларның торышын яхшыртырлык итеп тәэсир итәргә.

Үсемлекләр дөньясыннан файдаланучылар түбәндәгеләргә бурычлы:

үсемлекләр дөньясыннан файдалануның билгеләнгән кагыйдәләрен, нормаларын һәм вакытларын үтәргә;

үсемлекләр дөньясыннан файдаланганда табигый бергәлекнең бөтенлеген бозмый торган ысулларын кулланырга;

үсемлекләр дөньясы объектларының үсеш тирәлеге сыйфатын начарайтмаска яисә аның үрчү урыннарын бозмаска;

үсемлекләр дөньясының файдаланылучы объектларын исәпкә

алуны һәм аларның торышын бәяләүне, шулай ук аларның үсеш тирәлегенең торышын бәяләүне гамәлгә ашырырга;

үсемлекләр дөньясын үрчетүгә юнәлдерелгән тиешле комплекслы гамәлләр уздырырга;

үсемлекләр дөньясын саклауны гамәлгә ашыруда дәүләт органнарына һәрьяклап ярдәм күрсәтергә;

үсемлекләр дөньясы объектларын, шул исәптән сирәк очрый торган һәм юкка чыгу куркынычы булган объектларны саклауны һәм ишәйтүне тәэмин итәргә.

Законнарда каралган очракларда үсемлекләр дөньясыннан файдаланучыларның хокуклары арттырылырга яисә чикләнергә мөмкин.

<u>23 статья.</u> Урман хуҗалыгы

Урман хуҗалыгы - агач әзерләү, ягулык, азык-төлек, фармацевтика сәнәгате өчен чимал һәм башка продукция алу максатларында үсемлекләр дөньясыннан файдалану төре ул.

Урман хуҗалыгы өлкәсендәге мөнәсәбәтләр Татарстан Республикасының Урман кодексы һәм Татарстан Республикасы территориясендә гамәлдә булган башка норматив-хокукый актлар тарафыннан җайга салына.

<u>24 статья.</u> Кыргый техник һәм дару чималы әзерләү

Кыргый техник һәм дару чималы әзерләү - фармакология, җирле сәнәгать һәм эшчәнлекнең башка төрләре өчен чимал, шул исәптән кайры, туз, кабык, мүк, камыш, суүсемнәр һ.б. алу максатларында үсемлекләр дөньясыннан файдалану төре ул.

Әзерләргә рөхсәт ителгән дару үсемлекләренең исемлеге, әзерләүнең иң чик күләмнәре, үсемлекләр дөньясыннан файдалануның күрсәтелгән төрен җыю өчен таксалар Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты тарафыннан раслана.

Кыргый техник һәм дару чималы әзерләү өлкәсендәге эшчәнлекне гамәлгә ашыручы юридик һәм физик затлар күрсәтелгән эшчәнлекне гамәлгә ашыруның Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты тарафыннан билгеләнә торган тәртибен үтәргә тиешләр.

25 статья. Үсемлекләр дөньясыннан фәнни, мәдәни-агарту, тәрбияви, ял итү, савыктыру һәм зәүкый максатларда файдалану

Үсемлекләр дөньясы объектларын үсеш тирәлегеннән аермыйча, күзәтүнең, сурәткә төшерүнең төрле рәвешләрен һәм тикшеренүләрнең башка ысулларын кулланып, әгәр бу ысуллар үсемлекләр дөньясына һәм аларның үсеш тирәлегенә зыян китермәсә һәм үсемлекләр дөньясыннан, бүтән табигый байлыклардан файдаланучыларның хокукларын, шулай ук җир биләүчеләрнең (җирдән файдаланучыларның), урман фондын биләүчеләрнең хокукларын бозмаса, үсемлекләр дөньясыннан фәнни, мәдәни-агарту, тәрбияви, ял итү, савыктыру һәм зәүкый максатларда түләүсез һәм махсус рөхсәтсез файдаланырга мөмкин, моңа үсемлекләр дөньясыннан болай файдалану тыелган очраклар керми.

Фәнни, мәдәни-агарту, тәрбияви, ял итү, савыктыру һәм зәүкый максатларда үсемлекләр дөньясы объектларын табигый тирәлектән аерып алып файдалану бары тик Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты билгеле торган тәртип нигезендә генә рөхсәт ителә.

26 статья. Үсемлекләр дөньясы объектлары эшчәнлегенең файдалы үзенчәлекләрен куллану

Татарстан Республикасы территориясендә гамәлдә булган законнарда, хокукый-норматив актларда билгеләнгән очраклардан гайре, үсемлекләр дөньясы объектлары эшчәнлегенең файдалы үзенчәлекләре (яңа туфрак барлыкка китерү, тирәлекнең табигый санитарлары, атмосфераны беренчел халәтенә кайтару, биофильтратлар һ.б.) аларны үсеш тирәлегеннән аерып алмыйча гына кулланыла.

27 статья. Үсемлекләр дөньясы объектларыннан алар эшчәнлегенең продуктларын алу максатларында файдалану

Үсемлекләр дөньясы объектлары эшчәнлеге продуктларын (сагыз, каен суы, ширбәт һ.б.) алу өчен үсемлекләр дөньясы объек-

тларын үсеш тирәлегеннән аермыйча һәм аларны юкка чыгармыйча, шулай ук аларның үсеш тирәлеген бозмыйча гына файдалану рөхсәт ителә.

Үсемлекләр дөньясы объектлары эшчәнлегенең продуктларын алу максатларында алардан файдалану кагыйдәләре үсемлекләр дөньясын саклау һәм алардан нәтиҗәле файдалану әлкәсендә Татарстан Республикасының махсус вәкаләтле дәүләт органнары тарафыннан билгеләнә.

<u>28 статья.</u> Үсемлекләр дөньясы объектларыннан файдалануны туктату нигезләре һәм тәртибе

Түбәндәге очракларда үсемлекләр дөньясыннан файдалану туктатыла:

файдаланудан баш тартканда;

файдалануның билгеләнгән вакыты узгач;

Татарстан Республикасында әйләнә-тирә табигать мохитен саклау турындагы законнарны һәм үсемлекләр дөньясыннан файдалану өчен бирелгән лицензиядә күрсәтелгән үсемлекләр дөньясыннан файдалану шартларын бозганда;

үсемлекләр дөньясы объектларын саклауның үзенчәлекле режимнарын билгеләү максатларында аларны файдалануны туктату зарурлыгы килеп чыкканда;

файдалану хокукы бирелгән предприятие, учреждение, оешма бетерелгәндә.

Әлеге статьяның 1 өлешендәге 2, 3, 4 һәм 6 абзацларында каралган үсемлекләр дөньясыннан файдалану хокукы үсемлекләр дөньясыннан файдалану өчен тиешле органнар тарафыннан бирелгән лицензияләрне юкка чыгару юлы белән туктатыла.

Әлеге статьяның 1 өлешендәге 5 һәм 7 абзацларында каралган очракларда үсемлекләр дөньясыннан файдалану хокукы яклар килешүе нигезендә яисә суд тәртибендә лицензияне юкка чыгару юлы белән туктатыла.

## 5 бүлек.
## Үсемлекләр дөньясы объектларын саклауны һәм алардан файдалануны икътисадый җайга салу

29 статья. Үсемлекләр дөньясы объектларын саклауны һәм алардан файдалануны икътисадый җайга салуның максатлары һәм бурычлары

Үсемлекләр дөньясы объектларын саклауны һәм алардан файдалануны икътисадый җайга салу түбәндәгеләргә юнәлтелә:

үсемлекләр дөньясыннан файдаланган өчен түләүләр системасын төзүгә һәм үсемлекләр дөньясы объектларын саклауның, ишәйтүнең һәм алардан тотрыклы файдалануның даими икътисадый нигезен булдыруга;

үсемлекләр дөньясы объектларын саклау һәм алардан файдалану өлкәсендә дәүләт мәнфәгатьләрен икътисадый яклауга;

үсемлекләр дөньясыннан файдаланучыларны икътисадый яклауга.

30 статья. Үсемлекләр дөньясы объектларын саклауны һәм алардан файдалануны икътисадый җайга салу структурасы

Үсемлекләр дөньясы объектларын саклауны һәм алардан файдалануны икътисадый җайга салуга түбәндәгеләр керә:

үсемлекләр дөньясы объектларын исәпкә алу һәм икътисадый бәяләү;

үсемлекләр дөньясыннан файдаланган өчен түләүләр системасын икътисадый нигезләү;

үсемлекләр дөньясы объектларын саклау һәм ишәйтү гамәлләрен бюджеттан финанслау;

үсемлекләр дөньясын саклау һәм аннан файдалану турындагы законнарны бозган өчен штрафларның һәм дәгъваларның икътисадый нигезләнгән системасы;

үсемлекләр дөньясының законсыз юл белән кулга төшерелгән объектларын, шулай ук аларны эшкәртүдән алынган продукцияне конфискацияләп, аларны сатудан кергән акчаларны, шулай ук юридик һәм физик затларның ирекле кертемнәрен законнарда каралган

тәртиптә максатчыл файдалану.

31 статья. Үсемлекләр дөньясыннан файдаланган өчен түләүләр

Үсемлекләр дөньясыннан файдаланган өчен түләүләргә үсемлекләр дөньясыннан файдаланган өчен түләү керә.

Үсемлекләр дөньясыннан файдаланган өчен түләүләр кертү табигатьтән файдаланучыларны үсемлекләр дөньясы объектларын, аларның үсеш тирәлеген саклау буенча гамәлләрне үтәүдән һәм аларга китерелгән зыянны түләүдән азат итми.

Үсемлекләр дөньясыннан файдаланган өчен түләүләр Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты тарафыннан билгеләнә торган тәртиптә Татарстан Республикасының республика бюджетына һәм җирле бюджетларга керә.

Татарстан Республикасының республика бюджетына һәм җирле бюджетларга керүче акчалар үсемлекләр дөньясы объектларыннан комплекслы файдалану, аларны саклау һәм ишәйтү, зарарлы йогынтылардан саклау буенча тиешле программаларны, гамәлләрне башкару, үсемлекләр дөньясы объектларының дәүләт мониторингын алып бару, фәнни тикшеренү эшләре алып бару өчен, шулай ук үсемлекләр дөньясы объектларын һәм аларның яшәү тирәлеген саклауга, аларны ишәйтүгә һәм алардан тотрыклы файдалануга бәйле башка максатлар өчен кулланыла.

32 статья. Үсемлекләр дөньясы объектларын саклауны, ишәйтүне һәм алардан тотрыклы файдалануны икътисадый хуплау

Үсемлекләр дөньясы объектларын саклауны, ишәйтүне һәм алардан тотрыклы файдалануны икътисадый хуплауга түбәндәгеләр керә:

салымнар билгеләү һәм үсемлекләр дөньясы объектларын саклауны, ишәйтүне һәм алардан тотрыклы файдалануны тәэмин итүче, шулай ук үсемлекләр дөньясы объектларының үсеш тирәлеген һәм аларның торышын яхшыртучы юридик затларга һәм гражданнарга бирелә торган башка ташламаларны законнар нигезендә билгеләү;

үсемлекләр дөньясын нәтиҗәле саклаучы юридик затларга

ташламалы кредитлар бирүне куллану;

үсемлекләр дөньясын саклаучы урындагы затларны һәм гражданнарны матди хуплау.

Үсемлекләр дөньясы объектларын саклауны, ишәйтүне һәм алардан тотрыклы файдалануны икътисадый җайга салу гамәлләрен әзерләү һәм уздыру Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты тарафыннан башкарыла.

## 6 бүлек.
## Үсемлекләр дөньясын саклау һәм аннан файдалану турында Татарстан Республикасы законнарын бозган өчен җаваплылык

**33 статья.** Үсемлекләр дөньясы объектларына һәм аларның үсеш тирәлегенә зыян китергән өчен юридик затларның һәм гражданнарның җаваплылыгы

Үсемлекләр дөньясы объектларына һәм аларның үсеш тирәлегенә зыян китерүче юридик затлар һәм гражданнар законнар нигезендә җаваплы булалар.

**34 статья.** Үсемлекләр дөньясы объектларын саклау һәм алардан файдалану мәсьәләләре буенча бәхәсләрне хәл итү

Үсемлекләр дөньясы объектларын һәм аларның үсеш тирәлеген саклау һәм алардан файдалану, үсемлекләр дөньясын файдалануга бирү мәсьәләләре буенча бәхәсләр законнарда билгеләнгән тәртиптә суд яисә арбитраж суды тарафыннан хәл ителә.

**35 статья.** Үсеш тирәлегеннән законсыз зерып алынган үсемлекләр дөньясы объектларын һәм аларны казып чыгару коралларын тартып алу

Үсеш тирәлегеннән законсыз зерып алынган үсемлекләр дөньясы объектлары, аларның өлешләре, шулай ук үсемлекләр дөньясы объектларын законсыз казып чыгару кораллары законнарда билгеләнгән тәртиптә тартып алынырга тиеш.

## 7 бүлек. Халыкара шартнамәләр

36 статья. Халыкара шартнамәләр

Әгәр Татарстан Республикасы тарафыннан төзелгән халыкара шартнамәдә үсемлекләр дөньясын саклау һәм аннан файдалану өлкәсендә әлеге Закондагыдан башкарак кагыйдәләр билгеләнсә, халыкара шартнамә кагыйдәләре кулланыла.

Татарстан Республикасы
Президенты М.Шәймиев

Казан шәһәре,
1997 елның 18 сентябре
N 1303